ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 16.12.2016 г. Казань № 5-63/тэ

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының «2016-2018 елларда «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең җылылык энергиясен бирү хезмәтенә тарифлар билгеләү турында»гы 2015 елның 30 декабрендәге 5-48/тэ карары белән билгеләнгән «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең җылылык энергиясе бирү буенча хезмәтләренә 2017 елга озак вакытлы тарифларын корректировкалау турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190 - ФЗ санлы Федераль законга, «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләр хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынучы бәяләрне (тарифларны) исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2013 елның 13 июнендәге 760-э санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять күрсәткән җылылык энергиясен бирү буенча хезмәтләргә 2017 елда озак вакытлы тарифларны корректировкалау максатыннан чыгып, 2017 елга көйләнгән оешманың кирәкле планлы тулаем табышын ачыклап , Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2015 елның 30 декабрендәге «РСК» ЧҖҖ күрсәткән җылылык энергиясен бирү буенча хезмәтләргә 2016-2018 елларда тарифлар билгеләү турында» 5-48/тэ карарының 1нче кушымтасына үзгәрешләр кертергә һәм аны әлеге карарның кушымтасына ярашлы рәвештә яңа редакциядә бирергә.

2. Әлеге карар рәсми басылган көннән алып 10 көн эчендә үз көченә кертелә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2015 елның 16 декабрендәге 5-63/тэ карарына кушымта
“Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2015 елның 24 ноябрендәге 5-35/тэ карарына 1нче кушымта”

«РСК» чикләнгән җаваплылыктагы җәмгыятьнең 2016-2018 елларда җылылык энергиясен бирү буенча хезмәтләргә календарь чорга бүленгән тарифлары

| № п/п | Көйләнгән оешма исеме | Тариф төре | Ел | Җылылык йөртүче төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | пар |
| 1. | «РСК» Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять ( ЕТО-1* җылылык белән тәэмин итү системасына җылылык энергиясен бирү (тепловоды №№ 13, 14нче җылылык йөртүчеләр) | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциациясе булмаган очракта кулланучылар өчен | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/Гкал | с 01.01.2016 по 30.06.2016 | 7,00 | - |
| | | | с 01.07.2016 по 31.12.2016 | 7,04 | - |
| | | | с 01.01.2017 по 30.06.2017 | 7,04 | - |
| | | | с 01.07.2017 по 31.12.2017 | 8,90 | - |
| | | | с 01.01.2018 по 30.06.2018 | 7,30 | - |
| | | | с 01.07.2018 по 31.12.2018 | 7,49 | - |
| 2.1 | «РСК» Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять ( ЕТО-2* җылылык белән тәэмин итү системасына җылылык энергиясен бирү (магистраль җылылык челтәренә кушылган кулланучылар) | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциациясе булмаган очракта кулланучылар өчен | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/Гкал | с 01.01.2016 по 30.06.2016 | 185,00 | - |
| | | | с 01.07.2016 по 31.12.2016 | 189,17 | - |
| | | | с 01.01.2017 по 30.06.2017 | 189,17 | - |
| | | | с 01.07.2017 по 31.12.2017 | 3470,58 | - |
| | | | с 01.01.2018 по 30.06.2018 | 202,26 | - |
| | | | с 01.07.2018 по 31.12.2018 | 205,90 | - |
| 2.2 | «РСК» Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять ( ЕТО-2* җылылык белән тәэмин итү системасына | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциациясе булмаган очракта кулланучылар өчен | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/Гкал | с 01.01.2016 по 30.06.2016 | 799,99 | - |
| | | | с 01.07.2016 по 31.12.2016 | 801,03 | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | җылылык энергиясен бирү (магистраль җылылык челтәренә тоташтырылган кулланучылар (бүленүче җылылык челтәренә тоташтырылган кулланучылар) | | с 01.01.2017 по 30.06.2017 | 660,00 | - |
| | | | с 01.07.2017 по 31.12.2017 | 674,31 | - |
| | | | с 01.01.2018 по 30.06.2018 | 820,42 | - |
| | | | с 01.07.2018 по 31.12.2018 | 819,05 | - |

* - Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2015 елның 13 мартындагы 130нчы боерыгы белән расланган Казан шәһәрен җылылык белән тәэмин итү схемасы белән билгеләнгән;

** - Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2015 елның 13 мартындагы 130нчы боерыгы белән расланган Казан шәһәрен җылылык белән тәэмин итү схемасы белән билгеләнгән.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитетының тариф карарларын
кабул итүне оештыру, көйләү һәм
контрольлек итү бүлеге